РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» сентября 2021г. г. Альметьевск №45

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 150 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында » 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 150 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советеның 2015 елның 06 маендагы 178 номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге 11 номерлы, 2018 елның 17 июлендәге 124 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 127 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарның 3 пунктындагы уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым ташламасы бирелә торган сайланган объектлар турында хәбәрнамә, салым түләүче тарафыннан, салым органына үзенең сайлау буенча салым чорыннан башлап, салым ташламасы кулланыла торган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла. Салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә, салым органына дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.»;

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, ӘТатарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Мусин Р.Ф.) йөкләргә

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов